Шәһәр тибындагы Җәлил поселогы башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

11.04.2018 ел №5

**Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитетының «Социаль әһәмияткә ия эшчәнлекне гамәлгә ашыручы пенсионерларның, ветераннарның һәм инвалидларның җәмәгать оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы бюджеты акчасы исәбеннән субсидияләр бирү тәртибен раслау турында"гы 2018 елның 26 февралендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында»**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Җәлил шәһәр тибындагы поселогы муниципаль берәмлеге Уставы белән социаль әһәмияткә ия эшчәнлекне гамәлгә ашыручы пенсионерларның, ветераннарның һәм инвалидларның җәмәгать оешмалары чыгымнарын финанс белән тәэмин итү (каплау) максатларында, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы бюджеты акчасы исәбеннән социаль әһәмияткә ия эшчәнлекне гамәлгә ашыручы пенсионерларның, ветераннарның һәм инвалидларның җәмәгать оешмалары чыгымнарын финанслар белән тәэмин итүгә (каплауга) субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Тәртипнең 2 пунктында «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты карары нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Финанс бюджет палатасы» сүзләрен «Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты» сүзләренә алмаштырырга»;

2) 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 4 абзац өстәргә:

«Субсидияләр хисабына капланырга тиешле социаль әһәмияткә ия эшчәнлек ветераннарының һәм инвалидларның иҗтимагый оешмалары тарафыннан гамәлгә ашырыла торган чыгымнар Исемлеге Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты тарафыннан билгеләнә.»;

3) 8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Субсидияләр субсидияләр бирү турында килешү нигезендә яки Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башкарма комитеты тарафыннан субсидия алучы белән төзелә торган субсидия бирүдән баш тарту турында килешүләр нигезендә күчерелә.»;

4) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Килешүдә субсидия күләме, аның максатчан билгеләнеше, субсидия бирү сроклары һәм шартлары, субсидия алучылар тарафыннан субсидияләрдән файдалану турында хисап бирү тәртибе, сроклары һәм формасы, тикшерү үткәрүгә Башкарма комитет хокукы, субсидия бирү шартларын үтәү, субсидияләрне (субсидия калдыгын) кире кайтару тәртибе һәм сроклары, килешү шартларын бозган һәм субсидия алучылар тарафыннан бюджетка субсидияләр кайтаруны күздә тоткан шартнамә шартларын үтәмәгән өчен җаваплылык карала.»;

5) тәртипнең 10 пунктын киләсе редакциядә бәян итәргә:

«Чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә (каплауга) бирелә торган субсидия күләме иҗтимагый оешмалар тарафыннан гаризалар составында нигезләнә.».

2. Әлеге карарны махсус мәгълүмати стендларда халыкка игълан итәргә һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO.TATARSTAN.RU), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.

Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
башкарма комитеты җитәкчесе И.Ф. Галлямов